ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ДРОЖЖАНОВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЧҮПРӘЛЕ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

19.05.2021 с.Старое Дрожжаное № 199

Җир мөнәсәбәтләре өлкәсендә муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентларына үзгәрешләр кертү турында

«Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. «Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентларын раслау турында» Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Башкарма комитетының 2019 елның 27 июнендәге 271 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) муниципаль милектәге җир кишәрлеген милеккә бушлай бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентында;

муниципаль милектәге җир кишәрлеген түләүсез файдалануга бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентында;

муниципаль милектәге җир кишәрлеген торглар үткәрмичә сату буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентында;

муниципаль милектәге җир кишәрлеген торглар үткәрмичә генә арендага бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентында;

муниципаль милектә булган җир кишәрлеген, җир кишәрлегендә урнашкан биналар, корылмалар милекчеләренә милеккә яки арендага бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентында;

муниципаль милектәге җир кишәрлеген гражданнарның һәм крестьян (фермер) хуҗалыкларының милкенә (арендага) бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентында;

муниципаль милектәге җир кишәрлеген бакчачылыкны алып бару өчен гражданнарга милеккә (арендага) бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентында;

муниципаль милектәге җир кишәрлеген бакчачылыкны алып бару өчен гражданнарга милеккә (арендага) бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентында;

муниципаль милектәге җир кишәрлеген гражданнарга шәхси торак төзелеше өчен милеккә (арендага) бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентында:

**2.8 пунктының 9 пунктчасында** «төзелгән территорияне үстерү» сүзләрен «территорияне комплекслы үстерү» сүзләренә, «үзләштерү» сүзен «үсеш» сүзенә алмаштырырга;

**2.8 пунктындагы 10 пунктчада** «территорияне үзләштерү яисә төзелешне үстерү турында шартнамә» сүзләрен «үсеш» сүзенә алмаштырырга, «карала торган» сүзен «каралган» сүзенә алмаштырырга;

2) муниципаль милектә булган җир кишәрлеген даими (сроксыз) файдалануга бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентында **1 нче номерлы кушымтаны** төшереп калдырырга;

3) муниципаль милектә булган җир кишәрлеген милеккә бушлай бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентында **1 нче номерлы кушымтаны** төшереп калдырырга;

4) муниципаль милектә булган җир кишәрлеген түләүсез файдалануга бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентында **1 нче номерлы кушымтаны** төшереп калдырырга;

5) муниципаль милектә булган җир кишәрлеген торглар үткәрмичә сату буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентында **1 нче номерлы кушымтаны** төшереп калдырырга;

6) муниципаль милектәге җир кишәрлеген торглар үткәрмичә генә арендага бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентында **1 нче номерлы кушымтаны** төшереп калдырырга;

7) җир кишәрлекләрен милеккә бушлай бирү хокукына ия затлар буларак исәпкә кую буенча муниципаль хезмәт күрсәтү буенча административ регламентта **2.5 пунктының 4 пунктчасын** түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4) балаларның тууын дәүләт теркәвенә алу турында белешмәләр;»;

**2.6 пунктына** түбәндәге эчтәлекле **3 пунктча өстәргә:**

«3) тууны дәүләт теркәвенә алу турында белешмәләр.»

**2.6 пунктын** түбәндәге эчтәлекле **абзац белән тулыландырырга:**

«Әлеге пункт нигезләмәләре чит ил дәүләтенең компетентлы органнары тарафыннан бирелгән туу турындагы таныклыкларга һәм аларның нотариаль яктан расланган рус теленә тәрҗемәсенә кагылмый.».

2. Әлеге карарны хокукый мәгълүматның рәсми порталында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районының Мөлкәти һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы рәисенә йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе Д.А. Сатдинов